**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышев урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2023елның 11 апреле 1262 номер

# КАРАР

**Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Сокуры авыл җирлеге, Сокуры авылы, Державин урамы адресы буенча урнашкан кадастр номеры: 16:24:240301:3902 булган җир кишәрлеге территориясен ызанлау проектын әзерләү турында.**

Территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 41, 43, 45 статьялары нигезендә капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Сокуры авыл җирлеге, Сокуры авылы, Державин урамы адресы буенча урнашкан кадастр номеры 16:24:240301:3902 булган җир кишәрлеге территориясен ызанлау проектын әзерләүгә керешергә.

2. 2. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 43 статьясы нигезендә проектның эчтәлеген билгеләргә.

3. Гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) уздыруны исәпкә алып проектны әзерләү срогын 2023 елның 2 октябренә кадәр билгеләргә.

4. Физик һәм юридик затларга әлеге карар басылып чykканнан соң ундүрт көн эчендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына территорияне межалау проектының тәртибе, сроклары һәм эчтәлеге.

5. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы

хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**